**Габдулла Тукай: Фотоальбом / Төз. һ. фоторәс. авт. З. Бәширов; текст. авт. М. Мәһдиев.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.- 240 б.**

Татар халкының бөек шагыйре **Габдулла Тукай** дөньяда нибары егерме җиде ел яшәгән, бары тик сигез ел иҗат иткән — шулай да гасырларга җитәрлек рухи байлык калдырган. Зур картина ерактанрак караганда яхшырак күренгән кебек, Тукай иҗатының да еллар узган саен әһәмияте арта, бу шәхеснең олылыгы тагын да ачыграк төсмерләнә бара.

Тукай кебек зур шәхес ничек соң нәкъ егерменче гасыр башында килеп чыга алган? Бу хәл очраклымы? Тукайны бөек иткән шартлар, сәбәпләр кайда? Һәм алар нинди?

Гасырлар буенча халыкка хезмәт итәрлек иҗат тудыру өчен, һичшиксез, табигать тарафыннан бирелгән шагыйрьлек сәләтенә ия булырга кирәк. Яшь Габдуллага бу сыйфат исә юмарт бирелгән була. Талантны җәелдереп җибәрү өчен тиешле шартлар, мөмкинлекләр булуы да зарур. Анысын инде 1905 ел революциясе алып килгән хөрриятләр тудыра. Бер генә талантлы шагыйрь дә, әгәр аның иҗтимагый йөзе булмаса, ягъни халык мәнфәгатьләре өчен көрәш эчендә кайнамаса, иҗаты белән халыкка игелек күрсәтә алмый. Тукай исә үз замандашлары арасында шул зур иҗтимагый көрәштә иң актив катнашучыларның берсе була. Аның йөзләгән шигыре арасында нибары ике-өч кенә мәдхия бар. Шуларның берсе — татар халкының ялкынлы көрәшчесе большевик Хөсәен Ямашевка багышланган. Бу мәдхия Тукайның дөньяга карашларын, идеалларын ача да бирә.

Шагыйрь үзенең җәмгыятьтә нинди урын алып торганын турыдан-туры әйтә: «Мин бит... саф коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...»

## «Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин...»

Җир өчен, азатлык өчен көрәшләргә, патша самодержавиесенең камчылы экспедицияләренә гаҗәеп бай Казан артының үткәне. Бу төбәктәге халыкның аһ-зарлы моңы, яну-сөю аһәңнәре, акыл-хикмәт тулы җыр-бәетләр, әкият-мәзәкләр — һәммәсе дөньяви хәлләргә бәйләнгән.

Шагыйрьнең туган ягы — инешле, чокырлы, урманлы Казан арты. Монда әүвәл-әүвәлдән җирне урманнан яулап алганнар, җир азлыктан халык иза чиккән.

Монда зур сулар, зур болыннар да юк, биек таулар, кыялар да юк. Казан артының исә төп матурлыгы Шүрәлеле калын урманнарында; кырыенда тал куаклары сыгылып утырган, су анасы яши торган буаларында; офык артыннан мәһабәт Алып батыр кул болгап торган сыман күренгән җил тегермәннәрендә; тау асларыннан кеше гомерен санап тыйнак кына челтерәп агып яткан чишмәләрендә. Тагы бу якта унтугызынчы гасырның мәшһүр «Таһир-Зөһрә», «Бүзьегет» поэмалары туган, монда, бу як халкында «Кыйссаи Йосыф» дигән мәшһүр поэма күп мәртәбәләр күчерелгән, кулдан -кулга йөргән. Шул төбәкнең **Кушлавыч** авылында **1886** елның **26(14) апрелендә Мөхәммәтгариф** мулла гаиләсендә **Габдулла Тукай** дөньяга килә. Малай туып дүрт ай ярым үткәч, Мөхәммәтгариф хәзрәт үлеп китә. Тол калган **Мәмдүдәне** (Габдулланың әнисен) **Сасна** мулласына кияүгә бирәләр. Бәләкәй Габдулланы авылның Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыгына вакытлыча асрамага калдыралар. Әнә шуннан шагыйрьнең газаплы, авыр тормышы башлана. Дөньяда бер генә шагыйрьнең дә җылылык эзләп үз гомерендә җиде-сигез хатынга «әни» дип дәшеп караганы булмагандыр. Габдулла исә әнә шундый язмыш кичерә. Бераз соңрак аны үз әнисе яңа гаиләсенә алдыра. Шагыйрьнең «Исемдә калганнар» дигән автобиографик әсәрен укыганда шул урынга җиткәч, иркен сулап куясың: рәхәткә тарды сабый, дисең. Ләкин бу рәхәт озакка бармый: әнисе дөнья куя да Габдулла дөм ятим кала. Сасна мулласы бу ятимне **Өчилегә** — Габдулланың әнисенең атасына кайтарып бирә. Монда исә үги әби. Күп балалы гаилә. «Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине — җыласам — юатучы, иркәләним дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә — кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр...»

Бу булды дүртенче гаилә. Бәләкәй Габдулла монда ятимлекне генә түгел, ачлыкны да татый. Бабасы күрше авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтып балаларын ач үлемнән саклый. Ә бервакыт баланы **Казанга** баручы бер ямщикка утыртып ерак, билгесез сәфәргә озаталар. Теге ямщик исә Печән базарына килгәч: «Асрарга бала бирәм, кем ала?»— дип кычкырып йөри.

Халык арасыннан бер кеше чыгып малайны үзләренә алып кайта. Яңа бистә һөнәрчесе Мөхәммәтвәли абзый белән Газизә абыстай шулай итеп малайлы булалар. Тукай өчен бу исә — бишенче оя. Бәләкәй Габдулла бу гаиләсендә ике ел буена ярыйсы гына яшәгәч, тагын артып кала: әти-әнисе авырып китә һәм «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк...»— дип, аны яңадан **Өчилегә** озаталар. «Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу семьяның мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин». Тырыша торгач, малайны **Кырлай** исемле

авылдан ир баласыз Сәгъди абзыйга уллыкка озаталар. Шулай алтынчы оя...

Оядан ояга күчеп җылылык эзләп йөргән бу сабыйга Кырлай мәрхәмәтлерәк булып чыга. Беренчедән, бәләкәй Габдулла монда башка урыннарга караганда озаграк яши, хәтта сабакка йөри башлый. Икенчедән, Кырлай авылында ул үзенең киләчәк иҗаты өчен нигез булачак бик күп рухи байлык туплый. Шагыйрьне аңлап бетерәсегез килсә, аның туган ягына барыгыз, диләр. Шулай, әгәр Тукай иҗатын аңлыйсыгыз килсә, туган ягына барыгыз. Дөрес, бу якның табигате йөз ел эчендә байтак үзгәргән инде. Монда асфальт юллар, сарайлар, музейлар... Әмма Тукайның балачагында Кырлай янында куе кара урман булган әле. Ул урманга Кырлай малайлары белән бергә ат сакларга барулар, андагы учаклы, әкиятле, ябалак тавышларының шомлы ишетелгән сихри төннәре, таң алдыннан изелеп йокыга китүләр, сихри-мәһабәт күккә ашкан төз чыршылар һәм инде, бер дә шиксез, каяндыр гына малайларны күзәтеп торган Шүрәле — болар барысы да сизгер күңелле баланың ятимлек, каһәр белән имгәтелгән рухын баеталар. Крестьян хезмәте бик кызык ул: бер яктан авыр, газаплы. Ләкин шул газап янында хезмәт поэтикасы, игенчелек эшенең ләззәте: көн үзәгендә басудан кайткач тал астындагы буага төшеп кушаяклап тибеп йөзә-йөзә су керү... Баздан катык алып менеп, шуны чишмә суында болгатып салкын әйрән эчү... Ә теге буа, андагы хикмәтле тирән чоңгыллар... Ә кичләрен Кырлай урамында! Тальян гармунның осталары, халык җырларын бөтен нечкәлеге белән җырлаучылар, иң тирән моң, хәсрәтле моң — бары тик Казан артында гына... Казан арты төбәге, аеруча **Кырлай авылы** — Тукайны шагыйрь иткән шартларның иң әһәмиятлесе. Ак киндер алъяпкычлы, киндер бияләйле, татарча бүрек кигән эшчән Сәгъди абзый — Тукайга рухи азык биргән тыйнак, эшлекле татар крестьяннарының иң олы җан-лысы. Кырлай тирәсе — бөтен буа-чишмәләре, кара урманнары, уен-җырлары, йолалары белән Тукай-шагыйрьгә үз гомеренә җитәрлек рухи азык биргән.

Ерак җирләрдә гомер уздырып, яңадан Казан артына кайткач, шагыйрь туган ягы турында болай яза:

*Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,*

*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;*

*Һәр фосулы әрбәгъәң: язың, көзең, җәй, кыш көнең,*

*Барча, барча ак оек, киндер, чабата, ыштырың!*

*Һәм көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;*

*Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың .*

Шулай, рухи яктан авыл, крестьян тормышын тәмам күңеленә сеңдергән

Тукайны көннәрдән бер көнне Кушлавыч авылының Бәдретдин исемле кешесе эзләп таба да **Уральскигә** алып китә.

«Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмугъ кисәве булырсың»,— дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек».

Кайгы-хәсрәте, ятимлегендә изгән, сихри табигатендә рухи яктан баеткан бишеге белән саубуллашып Габдулла әнә шундый билгесез сәфәргә чыгып китә. Алда ниләр көтә инде бу ятимне?

Моны яшь Габдулла үзе дә, аны чанага утыртып алып баручы юньле, ипле кеше Алты-биш Сапый абзый да белми әле...

Алда — һөнәрчеләр, лавкалар тулы, мәчетле, чиркәүле, школалы, мәдрәсәле, милли-чуар Җаек — Уральск шәһәре. Хуш, Казан арты...

**Уральск** шәһәре Чаган елгасы Урал елгасына килеп кушылган җирдә урнашкан. Шәһәрнең беренче ташы салыну елы Романовлар династиясенә нигез салыну елына—1613 елга туры килә. Соңыннан, 1913 елда, Романовлар династиясенә 300 ел тулган көннәрдә Тукай үзенең гражданлык позициясенең иң югары ноктасы булган таләпчән усал шигырен язар. Уральск шәһәренең 1775 елга кадәрге исеме — **Җаек.** Екатерина II—Әби патша — бөтен Россияне дер селкетеп алган Пугачев восстаниесенең иң ышанычлы үзәге Җаек булганын бик яхшы хәтерли һәм бу шәһәрнең исемен тарихта юк итәргә тели. Әйтергә кирәк, анда яшәүче гади халык телендә бу шәһәр исеме гел Җаек булып кала.

Уральск шәһәре — сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр шәһәре. Дәүләт — империя өчен исә ул Урта Азия — Төркстан Сәхралары алдындагы капка, һәм шактый әһәмиятле капка. Бу капка Россия империясенең алда үткәреләчәк политикасына ышанычлы терәк — казаклар крепосте. Милли яктан чуарлык бик көчле: монда рус, казакъ, татар, украин, кыргыз, үзбәк, яһүди... Эчке Россия белән Урта Азияне тоташтыручы капка һәм әһәмиятле сәүдә юлларының өстендә корылган крепость буларак, монда тел белү, гыйлем өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Казакъ-кыргыз далаларыннан чимал җыю өчен, әлбәттә, алар белән аралашырлык сәләте булган татарлар сәүдә эшен җанландыру буенча беренче урында торалар. Баштарак бу далага вак сәүдә белән йөрүче Казан арты татарлары килеп чыга. XIX гасыр ахырларында, авылда экономик изү бик нык көчәйгәч, Казан арты халкы Уральск — Троицк төбәгенә ябырыла. Уральск татарлары, нигездә, Казан арты — Әтнә — Кенәр — Дөбъяз — Арча төбәге халкы. Болар — сәүдәгәр (тире-яры белән эш итәләр), болар — тегүче, мехчы.

Тукай барып урнашкан нигез дә Казан артыннан: апасы Газизә, җизнәсе Галиәсгар Госманов... Ә Уральск шәһәрендә өч мәдрәсә булган: «Мотыйгия», «Рәкыйбия» һәм «Гайния». Җизнәсе Тукайны «Мотыйгия»гә урнаштыра. Мондагы тормыш яшь Габдулланың рухына зур тәэсир ясый. Мәдрәсәдә әдәби рух бик көчле була, мәдрәсә хуҗасы Мотыйгулла хәзрәтнең өендә рояль тора. Тукай аның улы Камил белән тиз дуслаша. Камил исә — европача тәрбияле, коръән-хафиз (яттан белүче), җырчы, соңгы модада киенә, русчаны яхшы белә, гарәпчәне «су урынына эчә»...

Белемгә сусаган Тукай параллель рәвештә өчьеллык рус мәктәбенә кереп укый башлый. Мәдрәсәдә гарәп, төрек, фарсы телләрен бик яхшы үзләштергән малай кинәт кенә рус һәм Европа әдәбияты дөньясына чума.

Бик кызыклы әдәби язмышлар: XIX гасырның беренче чирегендә казачий войсковой атаман Мартемьян Бородинның улы Давид Италиядән архитектор Дельмединоны чакыртып Уральск шәһәрендә гүзәл бер бина төзетә. Ахырдан ул аны дәүләткә сата. Тукай укыган мәдрәсәдән ерак булмаган бу йортта тукталган кешеләр аның иҗатында, ничектер, аеруча зур роль уйныйлар. Әйтик, 1833 елның сентябрендә Уральскига коллежский асессор Владимир Иванович Даль (диңгезче, тел галиме, язучы) Пугачев тарихын өйрәнеп йөрүче Пушкинны алып килә, һәм алар шушы йортта тукталалар. Бу йортта шагыйрь В. А. Жуковский да булган икән. Ә Уральскида яшәгән бер графның улы белән Л. Н. Толстой бергә армиядә хезмәт иткән, һәм инде язучы булып танылгач, 1862 елда үзенең яшьлек дусты янына кунакка килгән. Толстой килү хөрмәтенә, озак та үтмичә Уральск шәһәрендә бакча эчендә ротонда төзиләр. В. А. Жуковский, А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой — Тукайның остазлары.

1905 ел революциясе дулкыннары Уральскига килеп җиткәндә, Тукайга 19 яшь була. Уральск халкы тарихта беренче мәртәбә ачыктан-ачык Беренче Май демонстрациясен уздыра. Аннан җәй уртасында, көздә тагын берничә мәртәбә халык җыелышлары булып ала. Замандашларының сөйләвенә караганда, халык демонстрациясен куып таратканда Тукайның җилкәсенә жандарм офицерының камчы очы да эләгә. Ике ел үткәч, Тукай моны искә алыр — Төркиягә китегез, дип киңәш биргән карагруһ министрларга шагыйрь болай дип җавап бирер:

*Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;*

*Камчылар — шул иске камчы, башкалык — тик фәсләре!*

Революция биргән мөмкинлекләрдән файдаланып Камил Мотыйгый «Уралец» дигән газета нәшриятын типографиясе-ние белән сатып ала. Тукайның тормышында яңа этап башлана, һәм ул типографиягә наборщик булып эшкә урнаша.

Уральск большевиклары бу типографияне революцион листовкалар тарату өчен файдаланалар. Тукай, шулай итеп, РСДРП членнары Коканов, Сенькин, Хвостов, Шиловларның кул астында эшли — революциядә катнаша. Ихтимал, шулар йогынтысындадыр, Тукай 1905—1907 елларда бик кыю-кыю публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясый. Уральск төбәгендәге кадимчеләр, байларны тәнкыйть итә, тынгысыз журналист буларак танылa. «Шартлар» дигән мәкаләсендә ул «Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатьтән пәрдә булып торуы бетмичә, мин үзебезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм»,— дип яза.

Уральск — шагыйрьнең журналист һәм шагыйрь буларак канат ныгыткан урыны. 1905 елның сентябрендә үк аның «Әлгасрелҗәдид» журналының реклама җыентыгында шигырьләре басыла. Ноябрьдә «Фикер» газетасы чыга башлый. Бераздан «Әлгасрелҗәдид» күренә. Тукай инде монысында фактик редактор. Хыялда сатирик журнал чыгару. 1906 елның июнендә анысы да («Уклар») дөнья күрә. Монда да фактик редактор — Тукай. Кыскасы, ул үз диңгезенә чума. Типографиядә кунып-төнеп эшли, берөзлексез шигырь, мәкалә яза, тәрҗемә итә. Уральск шагыйре Габдулла Тукайны инде Казанда, Оренбургта, Петербургта яхшы беләләр.

Әмма туган туфрак шагыйрьне Казанга тарта. Сигез яшендә калдырып чыгып киткән Казан шәһәре аңа белем учагы, культура учагы булып күренә һәм Уральскида язган «Пар ат» шигырендә аның инде рухы белән Казанда яши башлаганлыгы күренә.

Һәм 1907 елның сары яфраклар белән түшәлгән Казан урамына атлы повозкага утырып Тукай килеп керә. Еллар, еллар... Чыпта белән капланган чанада Уральскига кадәр озын юл үткән малай — туган ягына өлгергән журналист, канатлары ныгыган шагыйрь, ачы телле сатирик булып, политик көрәшче һәм публицист булып кайтып керә.

Казан газета-журналларында эшләү өчен татар әдәби һәм сөйләм телен, рус, гарәп, фарсы, төрек телләрен белгән тәҗрибәле шагыйрь һәм публицист кайтты. Исәнме, **Казан!**

*«Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеге вә шунда бару хакында шигырьләр яздыкым Казанда инде!.. Монда күңелле. Дуст-иш, зыялылар күп, сөйләшәбез, көлешәбез, укыйбыз...»*

(1907 ел, Г. Кариевка язган хатыннан).

1907 елның көзеннән Тукайның **Казан** чоры — халкына, Ватанына шигъри сүзен әйтер өчен бирелгән биш ел да сигез айлык дәвере башлана. Казан... Ул — нинди шәһәр, аның нинди үзенчәлекләре, нинди культурасы, рухи байлыгы бар? Казан үзенең мәшһүр университеты, андагы математика, химия мәктәбе белән бөтен Россия империясенең гыйлем үзәкләреннән берсе була. Университетның типографиясе татар һәм Урта Азия — Казакъстан халыклары өчен бик күп уку китаплары, дәреслекләр бастырып бу халыкларны агартуга зур өлеш кертә. Университеттагы Көнчыгыш факультетында демократик карашлы зур галимнәр эшли. Тукайга университет зур тәэсир ясагандыр: монда бит профессор Готвальдлар, Катановлар һ. б. белән Мәрҗаниләр, Насыйрилар Болгар тарихын, татар фольклорын өйрәнгәннәр. Тукай Казанга килүгә «Әль-ислах» газетасында, «Яшен» журналында актив катнаша башлый. Яңа дуслар да табыла. Болар: Ф. Әмирхан, Х. Яма-шев, К. Бәкер, В. Бәхтияров, Г. Камал, С. Рах-манколый, Г. Коләхметов, бераз соңрак — С. Сүнчәләй. Үзе теләгән әдәбият, журналистика өлкәсенә чума.

Шул чорда Тукай белән Ф. Әмирхан арасында кыска, ләкин мәңгелек дуслык урнаша. Тукайның дөньяга карашларын алга таба үстерүдә иң зур рольне, әлбәттә, акыллы, тәҗрибәле Фатих Әмирхан уйнаган.

Ф. Әмирхан, Г. Камал ерак Уральскидан килгән Тукайны Казан һәм аның эчке дөньясы белән таныштыралар, эчкерсез күңелле яңа дуска эшлекле киңәшләр бирәләр...

Тукай килгәнче Казанда халык әдәбияты, балалар әдәбияты мәсьәләләре беркайчан да проблема итеп күтәрелмәгән була әле. Дөрес, халык кулында балалар яратып укый торган К. Насыйри, С. Рахманколый, Т. Яхин китаплары, аерым хрестоматияләр була. Казанның әдәби көчләре дә инде байтак танылган: Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г, Коләхметовлар инде билгеле талантлар. Казан — университетлы, институтлы, берничә гимназияле, күп сандагы реальное училищелы, мәдрәсәле, бик күп клублы, әллә ничә төрле җәмгыятьле шәһәр. Әллә ничә газета-журнал, әллә ничә типография бар анда. Тукай Казанга килгәч тә әнә шул культура-мәгърифәт атмосферасына чумып иң кирәкле ике юнәлешне сайлап ала: халык әдәбиятын күтәрү һәм яшь буын өчен әсәрләр, уку китаплары, дәреслекләр язу. Тукай балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнү, бастырып чыгару эшенә нигез сала. Аның Казандагы кыска гомерендә балалар өчен булган унөч, халык иҗаты буенча дүрт, барлыгы утыздан артык китабы басылып чыга.

Казанда Тукайның энергиясе яңа, киң мәйдан сорый. 1910 елның башында

журналист Әхмәт Урманчиев редакторлыгында сатирик журнал «Ялт-йолт» чыга башлый. Тукай бөтен көчен шушы журналга бирә, сатирик әсәрләренең бик күбесе «Ялт-йолт»та басыла. Ул шәһәрнең иҗтимагый эшләрендә актив катнаша, әйтик, «Шәрык клубы» программасындагы кичәләрдә концертлар, лекцияләрне оештыруда Г. Коләхметов, Ф. Әмирхан, Ф. Агеев, С. Рахманколый кебек алдынгы карашлы яшьләр белән бергә эшли. Концертларда үзе чыгыш ясый. 1910 елның 15 апрелендә «Шәрык клубы»нда халык иҗаты буенча лекция укып, шәһәр яшьләрен таң калдыра. Шагыйрь үзенең табигый фикер әзерлеге белән илдә яңа революцион күтәрелеш башланганны тоеп ала. Әле генә кара реакция эзәрлекләүләре, тикшерүләр, төрмәләр, судлар белән тетрәнеп алган татар яшьләре каршына чыгып Тукай тарихи оптимизм тулы сүзләрен әйтә:

*«Дөресен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул,*
*дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул».*

Тукай поэзиясенең чәчәк аткан вакыты, әлбәттә, Казан чоры. Китап наширләре алдан ук аның әсәрләрен басарга вәгъдә биреп торалар, аның әсәрләрен Оренбургтагы «Шура» белән «Вакыт» та, Казандагы «Йолдыз» да күтеп кенә тора. Ихтимал, Г. Камал йогынтысындадыр (ул «Йолдыз» редакциясендә эшли), Тукайның социаль характердагы бик күп шигырьләре либераль юнәлештәге «Йолдыз»да басыла. Социаль-политик эчтәлекле «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре», «Көзге җилләр» кебек иң көчле шигырьләренең бу газетада басылуы шулай уйларга нигез бирә. Тукайның шагыйрь буларак дәрәҗәсе шулкадәр зур югарылыкка менә ки, байлар акчасына чыгып килгән дини-фәлсәфи-әдәби-политик журнал «Шура» Тукайның байларны тәнкыйть иткән үткен социаль мотивлы «Сайфия» шигырен дөньяга чыгара. Татар театрының эшчәнлегенә дә Тукай зур игътибар бирә. Театрның үзәгендә төп фигура — Тукайның яшьтәше һәм Уральскидагы сабакташы Габдулла Кариев. Театрда әсәрләрен куйдыручы, кайбер спектакльләрдә үзе дә уйнаучы — Г. Камал. Тукайның Казанга килгәч язган иң әүвәлге шигырьләреннән берсе театр турында. Театрның әһәмиятен Тукай әхлакый яктан гына түгел, социаль караштан чыгып та билгели. Тукайның «Болгар»да торганда да, «Амур»да яшәгәндә дә бүлмәсе буш булмый. Татар интеллигенциясенең мондый җыелышларын яшерен агентура аркылы жандармерия һәм полиция күзәтеп тора. Кунакларның төрлесе була. Шагыйрь үз тирәсендә йөргән бушбугаз милләтчеләрдән, эшлексез гайбәтчеләрдән качарга тырыша. Әмма бүлмәсенә Хөсәен Ямашев килгән минутларны ул гомерендәге иң якты минутлардан исәпли.

*Мин — кунакчыл бер җыручы, миндә — бар ярлы-гидай,*
*Ханәмә яшьләр килә, һәм сәүдәгәр, бай угълы бай.*
*Ул бәләнд мәрхүм дә килсә, мин сизә торган идем:*
*Күктән иңгән, ханәмә килгән шикелле тулган ай.*

Кызганычка каршы, Тукайның әйләнә-тирәсендә гел Хөсәен, Әмирхан, Гафур һәм Камаллар гына булмый. Казан — чуар шәһәр, анда пролетарий, марксист-большевик, галим-профессор, җор сәүдәгәр, корсагын киергән татар бае, поп-академик, киезката кигән меңләгән шәкерт, картуз кигән студент, бәхет эзләп килгән йомышчы малайлар, ак манжетлы интеллигент, ачлы-туклы журналист һ. б. бик күпләр яши. Шул чуар корама эчендә бушбугаз милләтчеләр, кадимчеләр, бохарачы-төрекчеләр, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр гөжли, аваз сала. Соңгыларының җыела торган урыны — Тукай яшәгән «Болгар» номерларының тәрәзә астында гына — Печән базары. Печән базары... Анысы тагын ни? Шәһәрдә печән нигә? Ләкин бит без бүгенге шәһәр турында сүз алып бармыйбыз. Егерменче гасыр башында Казан бистәләрендә әле халык мал-туар асрый: һәр йортта сыер, сарык, кәҗә. Болак арты халкы ат асрый. Андый шәһәрдә «Печән базар»сыз мөмкин түгел. Печән саткан авыл халкына товар кирәк. Печән базары кибетләрендә — төрле товар — кармактан алып комган, намазлыкка кадәр. Барысы да иске тип сәүдәгәрләр, «без — мөселман» дип үзләренен кадимлегенә шөкер итеп утыручы искеләр. Болар тирәсендә милләтче укымышлылар, бушбугазлар йөри. Болар яңалыкка — театр, концерт, европача модага, русча өйрәнүгә каршы. Монда шымчылар, алдакчылар байтак. Болар арасыннан да Тукай бүлмәсенә кереп йөрүчеләр бар. Бу атмосферада Тукайның тыны буыла, Печән базары аңа татар тормышының артталыгы символы булып күренә башлый. Шулай да Печән базары Тукай иҗатына зур файда китерә: сатирик әдәбиятыбызның иң гүзәл үрнәге булган «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы язылуга сәбәп була. Тукай бу әсәрендә Казан шәһәрендәге искелек пәрдәсен күтәреп халыкка күрсәтә. Бу поэманы «Купеческое собрание» бинасында халык алдында укып ул үзенә мәңгелек шөһрәт казана. Шәрәфләр исә Тукай белән шул ук кичтә сөйләшәләр һәм атна-ун көн дигәндә китапны бастырып та чыгаралар. Казан шәһәре Тукайның дөньяга карашын бик нык тирәнәйтә. Казанда ул күп төрле рухи халәт кичерә: дәртле эш, кара реакция елларында вакыты-вакыты белән күңел төшенкелеге, унынчы еллардан соң янә күңел күтәренкелеге, якты өметләр...

Кайвакытта, Казан атмосферасында эче пошып, Тукай сәяхәткә чыгып китә:

Нижний Новгородка Мәкәрҗә ярминкәсенә барып килә; Сембер губернасында Гурьевка фабрикасында була; Әстерханга Сәгыйть Рәмиев янына кунакка бара. Шәһәрдә булганда да гел хәрәкәттә: әле «Шәрык клубы»нда концертта катнаша; әле «Мөхәммәдия» шәкертләре алдында чыгыш ясый; Крестовниковлар заводы белән таныша. 1911 елның ахыры — 1912 елның башында Өчиледә яшәп ала, авыл халкының авыр, газаплы тормышын чагылдырган әсәрләр яза.

Күптәннән килгән үпкә авыруы көннән-көн көчәя. Шуның өстенә 1912 елның мартында зур фаҗига кичерә: ул «әүлия» дип атаган Хөсәен Ямашев — татар халкының иң гүзәл улларыннан берсе — кинәт үлеп китә. Бу көтелмәгән үлем Казан яшьләрен тетрәндереп җибәрә. Тукай Хөсәенгә багышлап ике шигырь яза. Ямашев үлгәч, ничек-тер, дөньядан күңеле бизеп китә. Ул сәяхәткә чыга, Уфада, Петербургта була, аннан тагын Уфага килә. Дусларының киңәшен тотып, сәламәтлеген кайгырта башлый, казакъ даласына барып кымыз эчә. Бу йөрүләр, бу сәяхәтләр нәтиҗәсе буларак, искиткеч бай тасвирлы юлъязмалар циклы туа. Шулай да гомер елларының инде санаулы гына калганын Тукай аңлый. Дөресрәге — айларының. Шуңа күрә, бер генә көнен дә әрәм итми, халыкка әйтәсе сүзләрен әйтеп бетерергә ашыга. 1912 елның җәендә Ф. Әмирхан белән бергәләп яңа әдәби-сәнгать журналы чыгарырга ниятләнәләр. Моның нашире итеп шул заманның алдынгы фикерле укымышлысы Әхмәтгәрәй Хәсәнине күндерәләр. Хәсәниләрнең Аккош күле янындагы дачасында мондый карар кабул ителә: журналны «Аң» дип исемләргә. Тукай аның беренче саны өчен махсус шигырь яза.

*Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул;*
*Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын аң белән.*

1913 елның башында шагыйрьнең сәламәтлеге бик нык какшый. Ләкин ул иҗат эшен туктатмый. Тукайның соңгы айларында язган әсәрләре аның чын мәгънәсендә зур патриот, гражданин һәм тарихны тирәнтен аңлаган шәхес икәнен исбат итәләр. Аның иң соңгы шигырьләрендә кат-кат Лев Толстойга мөрәҗәгать итүе, Шиһабетдин Мәрҗани шәхесе турында язуы, «Уянгач беренче эшем», «Юбилей мөнәсәбәте белән», «Ике ихтар» кебек публицистикасы һәм «Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре», «Суык» шигырьләре — чын мәгънәсендә шедеврлар. Бу — шагыйрьнең үз гомеренә йомгак ясавы, әйтәсе килгәнне әйтеп калырга омтылуы. Тукай Клячкин больницасына кергәндә дә үзенең соңгы «сәяхәткә» чыгуын аңлап китә. Иртәгә больницага ятар алдыннан ул «Амур»дагы күршесе Ф. Әмирхан янына керә. Әмирхан аңа:

— Тиз терелеп чык, тиз күрешик! — дигәч, Тукай:

— Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә,—ди...

**15 (2) апрельдә** Тукайның гомере өзелә. Казан шәһәренең моңа кадәр андый күп халык җыйган җеназа күргәне булмый. Авылларда, шәһәр мәдрәсәләрендә Тукайны күмгән көнне дәресләр уздырылмый. Матбугат органнары илнең төрле почмакларыннан килгән кайгы телеграммалары белән күмелә. Мәскәү, Петербургта чыккан рус матбугатында бу турыда хәбәрләр күренә. Бигрәк тә «Мусульманская газета» бу кайгылы хәлгә күп урын бирә. Анда телеграммалардан тыш Тукайга багышланган русча шигырьләр басыла. Рус һәм чит ил матбугаты Тукай шәхесе белән кызыксына башлый. Петербург газетасы «День» Тукайны «Татарский Пушкин» дип атап зур мәкалә бастыра. «Восточный сборник» дигән академик җыентыкта Тукайның биографиясе, берничә шигырьнең русчага тәрҗемәсе бирелә. Лондонда чыга торган «Тһе Russian Review» (Рус журналы) 1914 елда Тукай турында мәгълүмат бирә, аның «Пар ат» шигырен инглизчә бастыра. Тукай турында Төркия матбугатында күп языла...

Казан шәһәренең бүген Островский исеме белән йөртелгән урамындагы больницадан Тукайны Яңа бистә зиратына озаталар. 1912 елда шагыйрь болай язган иде:

*Язганың булса бәкалы, ул бәкага тартыла;*
*Мин дә булдым һич тә онтылмас кеше шул аркада.*

***«Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора...»***

(1911 ел, С. Сунчәләйгә язган хатыннан).

Тукай исеме, ничектер, үзеннән-үзе халыкның культурасын, әдәбият-сәнгатен берләштерүче, оештыручы мәгънәви бер уртак исемгә әйләнде. Бу тенденция 1913 елдан соң ук шул юнәлештә үсеп китте, халык аның турында бәет чыгарды, күп шагыйрьләр аңа багышлап шигырь яздылар. Революциядән соңгы елларда Тукай иҗаты формасы буенча милли, эчтәлеге буенча социалистик булган культурабызны оештыручы иң әһәмиятле бер чыганак булды. Совет власте елларында Тукай әсәрләре күп тапкырлар басылды, зур басмаларыннан берсе хәтта авыр сугыш елларында да (1943) дөнья күрде. Татар солдатларының аркасындагы капчыкта Тукай китабы Мәскәү яны, Курск дугасы, Берлин сугышларын күрде. Белоруссия, Украина фронты сугышчыларының татар халкына хатларында яки татар халкының боларга җавапларында Тукайның кайнар патриотик шигырьләре үзәк урынны алды. Тукай иҗаты бүгенге космос, кибернетика заманында да яши, үзенең активлыгын югалтмый. Нигә шулай? Чөнки бу бөек иҗат — интернациональ иҗат. Бөек Тукайның әкият-

поэмасына таянып Фәрит Яруллин иҗат иткән **«Шүрәле»** балеты илебез сәхнәләреннән чыгып Көнбатышта йөреп кайтты, һәрвакыт югары уңыш казанды. Тукай җырлары бүген Европада, Африкада яңгырый: бер дә гаҗәп түгел, аны яңгыратучылар — Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе оркестры, Җыр һәм бию ансамбле. Алар Тукай моңын Африка, Мальта, Италия тамашачыларына җиткерделәр. Финляндиядә күптән инде Советлар Союзы белән культура арадашлыгы органының бер бүлеге — «Тукай җәмгыяте» яшәп килә. Шунысы кызык, Тукай иҗаты сәнгатьнең барлык төрләренә дә уңай тәэсир ясый, аларны баета, үсәргә ярдәм итә. Ф. Яруллинның «Шүрәле»се, Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш», Ә. Бакировның «Алтын тарак» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» исемле зур күләмле симфониясе, рәссамнар И. Казаков, Б. Альменов, Ф. Әминев әсәрләре, скульптор һәм рәссам Б. Урманче иҗаты — Тукай иҗатының бетмәс-төкәнмәс ильһам чыганагы икәнлегенә дәлил.

Тукай театр сәхнәсендә дә яши, тарихи романнарда да яши. Татарстанда иҗат ителгән иң яхшы әдәбият, сәнгать әсәрләре өчен Тукай туган көндә әдәбият, сәнгать эһелләренә ел саен **Габдулла Тукай** исемендәге **Дәүләт премиясе** бирелә. Казанның иң борынгы урамнарыннан берсенә Тукай исеме бирелгән. Татарстанның элекке Чаллы районы РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә Тукай районы дип аталды. Тукай исеме белән аталган урам Казакъстан ССРның Уральск шәһәрендә дә, Ташкентта да бар. Халыкның үз шагыйренә булган хөрмәте бигрәк тә язгы айларда — ул туган көннәрдә сизелә, һәр елның 26 апрелендә Татарстан язучылары җыелышып Казан шәһәрендәге бөек шәхесләрнең һәйкәлләренә чәчәк куялар. Ленин, Пушкин, Горький, Тукай, Җәлил... Бер төркем язучылар шул көнне Кырлайда, Арчада, Тукай районында митингларда чыгыш ясыйлар. Шундый ук бәйрәмнәр Түбән Кама, Әлмәт, Яр Чаллы шәһәрләрендә дә уздырыла. Шигырь бәйрәме М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Тукай һәйкәле янында дәвам итә. Монда халык Габдулла Тукай премиясенә лаек булган яңа лауреатлар белән таныша. Тукай, әнә шулай, халкы белән бүген дә бергә атлый.